# МӘКТӘП ДУЛКЫНЫНДА

***Куәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№7 Май 2023 ел*



## Рәхмәт Сезгә сугыш ветераннары!



Хөрмәтле ветераннарыбыз! Барыбыз өчен дә иң изге бәйрәмнәребезнең берсе - күпмилләтле халкыбызның Бөек Ватан сугышында Җиңү көне белән котлыйбыз! Күрсәткән батырлыкларыгыз , тырыш хезмәтегез өчен сезнең алдыгызда башыбызны иябез. Сез фашизмны җимереп һәм дөнья тарихын үзгәртеп кенә калмадыгыз. Сез киләчәк буыннарга тормыш һәм азатлык бүләк иттегез. Чын күңелдән сезгә ныклы сәламәтлек һәм озын гомер телибез!
Бөек бәйрәм белән Сезне!

## Хәерле юллар укучыларыбыз!



Мәктәп еллары!
Нинди гүзәл көннәр!
Тупланганнар аңа барысы да:
Укучының кайгы-шатлыклары,
Яшь кызларның сагышы…
Шау-гөр килеп узган кичәләр,

Яшьләрнең шат, шаян җырлары,
Яшь кызларның керсез хыяллары,
Җырлап үткән мәктәп еллары.
Синдә кала, барысы синдә кала
Гүзәл уку, мәктәп еллары!!!

## Музейга экскурсия.



Без сыйныфыбыз белән Күлле-Киме авылына Сибгат Хәким музеена экскурсиягә бардык. Безне анда музей җитәкчесе Гөлсинә апа каршы алды. Аннан без музейга кердек. Ул шундый зур һәм матур. Гөлсинә апа безне башта Сибгат Хәкимнең тормыш юлы, шәҗәрәсе белән таныштырды. Без анда элеккеге авыл өе күренешен күрдек. Агачтан ясалган бала арбасы, чуеннар, кер юа, май ясый торган җайланмалар, игенченең эш коралларын бик кызыкынып карадык. Безгә аларны тотып карарга да рөхсәт иттеләр. Аннан Сибгат абыйның сугыш чоры тормышы турында тыңладык.



Солдат флягасы, каска, тимер тәлинкәләрнең үз тарихы бар иде. Аннан Сибгат абыйның эш өстәлен, язу машинкасында баскалап та карадык. Сибгат абыйның туган авылына кайтуы турында видеофильм карагач, Гөлсинә апага рәхмәт әйтеп, мәктәпкә кайтып киттек.

Загидуллина Ралинә, 2 сыйныф.

## Рәхмәт Сезгә беренче укытучыбыз !




2019 елның 1 сентябрендә, мин нәни кулларыма чәчәк бәйләме тотып, өстемә ак күлмәк киеп, галстук тагып кечкенә генә шук малай “зур егет” булып 1 сыйныфка укырга Куәм мәктәбенә килдем.

Безне елмаеп укучыларым дип, Римма апабыз каршы алды.Ул безне, без аны бик яраттык.
4 ел сизелмичә дә узып китте.Без бүген зур егет –кызлар булып 4 нче сыйныфны тәмамладык.
Башлангыч сыйныфта укыганда төрле ярышларда, олимпиадаларда, конкурсларда катнаштык.Шатланырлык нәтиҗәләребез бик күп булды.Уку буенча да, спортта да сынатмадык.Һәр бәйрәмне апабыз белән бергәләп бик күңелле, истә калырлык итеп үткәрдек.”Үрдәк беренчелекне” алган исемле спектакль да куйдык.
Инде менә саубуллашу көннәре. Безгә бик күңелсез. Ләкин без Римма апабызны онытмабыз.Ана тазалык саулык кына телибез.Озак еллар әле ул безнең белән булыр.

Шакиров Раяз ,4 сыйныф

## Әбием белән горурланам!

Минем әбием Шигапова Назирә Хәмбәл кызы. Ул гомере буе укытучы булып эшләгән. Аның даны бик күп җирләргә таралган,чөнки ул белем биргән укучылар хәзерге көндә төрле өлкәләрдә яшиләр һәм эшлиләр.Әбием алардан бары яхшы хәбәрләр генә ишетеп,куанып тора.
Әбиемнең биографиясенә килгәндә ул бик гади. Әбием Дусымның башлангыч һәм Куәм сигезъеллык мәктәбендә белем алган.Мәктәпне тәмамлагач Арча педагогия көллиятенә укырга кергән. Аннары 1973 елда Дусым башлангыч мәктәбенә эшкә кайта. Шул ук вакытта география фәне буенча югары уку йортында белемен киңәйтә.1978 елда Олы Әтнә Урта мәктәбендә эшли башлый,ул анда 6 ел белем бирә. Аннары гаилә коргач, Куәм урта гомуми белем бирү мәктәбендә эшли,шул дәвердән бирле әбием 25 елны шушы мәктәптә хезмәт итә.
Күп еллар инде әбием лаеклы ялда.Мәктәптә үткән көннәрен ул яратып искә ала. “ Бергә эшләгән хезмәттәшләремне күрсәм дә,күзләрдән яшьләр килә. Хәзерге көндә өч оныгым шушы ук мәктәптә укыганга куанып, горурланып торам” -дип сөйли әбием. Ә без үз чиратыбызда аңа сәламәтлек, хәерле озын,тигез гомер телибез!

Шигапов Фәнил, 7 сыйныф

## Уңышлар телибез!

Менә 4 нче чирекнең ахыргы көннәре. Сизелмичә генә уку елы да узып китте. Чирек ахырында һәр укучы үзенең билгесен яхшырту өстендә эшли. Барлык укучылар да каникулларны зарыгып көтәләр. Һәр укучының 4 нче чирекне һәм уку елын уңышлы тәмамлавын теләп калабыз.

Брча Айша, 5 сыйныф

## Без һәрвакыт әзер!!!




Май аенда бәйрәмнәр күп. Шуларның берсе - 19 Май Пионерия туган көн. Класс сәгатьләрендә без пионериянең тарихы, герой пионерлар турында өйрәнәбез. Күргәзмәләр эшләү өчен эзләнү эшләре алып барабыз. Без төрле истәлекле открыткалар һәм күп кенә фотолар тупладык. Чөнки безнең эти әниләребез пионер булган буын, пионерларның һәркайда бердәм булып, файдалы эшләр башкаруларын белдек. Истәлекләрнең кайберләре мәктәпнең туган як музеенда урын алган. Һәр фотоның үз аерым тарихы бар. Иң күп фотоларны мин гаилә альбомыннан таптым, әни белән бергә аларны карап чыктык. Чөнки минем дәү әнием укытучы булган. Аның укучылар, пионерлар белән бергә төшкән фотолары байтак. Ул чордагы укучылар инде күбесе өлкән яшьтә. Ул пионерлар тимурчылар да булганнар, төрле җәмәгать эшләрендә актив катнашканнар. Пионерларның отряд һәм дружина сборлары уздырылган. Һәр отрядта отряд кенәлеге алып барылган. Анда төрле эшләнгән эшләр язып барылган. Андый көндәлекләрдән ветеран укытучы Фәизов Фәргать абый сыйныфының Самат Шакир исемендәге отряд көндәлеген карадык. Күәм урта мәктәбендә күп еллар пионервожатый булып эшләгән Шигапова Зәлфирә апайның истәлекләрен укып таныштык. Ветеран укытучылар, аларның хезмәт юлы белән танышу максатыннан, материаллар туплауны да дәвам итәбез. Тарихны өйрәнү һәм белү бүгенге буын укучылары өчен бик кирәк. Барлык игелекле эшләребез дәвамлы булсын. Җәмгыятькә файдалы эшләр башкарып, куйган максатларга ирешерергә тырышырбыз.

Камаева Ләйлә, 8 сыйныф

Һәр нигезнең, һәр авылның, Һәр каланың үткәне бар...
Гыйбрәт алырлык мирасның калганы бар, киткәне бар.
Горур сүз әйт, сорасалар: Ни кавемнән? Нинди җирдән?
Киләчәккә аек карап Үз тарихын анык белгән!
Р.Фәйзуллин..



Без классыбыз белән искиткеч экскурсиягә бардык. Әтнә районы Бәрәскә авылы мәчетен күрү, тарихы белән танышу бәхетенә ирештек. Шушы истәлекле очрашуны оештырганнары өчен үзебезнең мәктәбебез директорына, укытучыларыбызга рәхмәтебезне җиткерәбез. 6 сыйныф укучылары.

## Сүзем хөрмәтле укытучым турында!

Укучым Фәнилнең язмасы кулга килеп керү белән Назира апа турында әйтми калу дөрес булмас дип уйладым. Назира Хәмбәл кызы минем дә беренче сыйныф җитәкчем иде. Назира апай безне, 18 укучыны, кабул итеп алгач, тирән белемле, дөрес тәрбияле, әхлаклы булырга өйрәтте. Беренче тапкыр хәрефләрнең язылышын, әйтелешен сабыр гына итеп аңлата белде. Безнең сыйныф бик җитез, тик тормас, актив иде. Бар яктан да булган сыйныф дисәм дә ялгыш булмас.Спорт буенча, бию буенча, укуда да гел мактау тактасыннан төшмәдек. Ара-тирә шаярулар аркасында линейка вакытларында да исемнәребез яңгырады. ”Мәктәп чыңы” тактасында комикслар чыгаруда безнең сыйныф беренче иде. Назира апа шундый укучыларны үстереп, белемле итеп безне 4 нче сыйныфтан озатты. Әлеге көндә дә без аңа рәхмәтле, аның алдында баш иябез.Тормышта һәр балага шундый Назира апай кебек Беренче укытучылар насыйп булсын дигән теләктә калам.

Гайнетдинова Алия, сыйныф җитәкчесе


## **Халык сынамышлары**

- Май аенда яңгырлар күп яуса, сентябрь коры килер, һәм киресенчә.
- Шомырт чәчәк атканда һәрвакыт салкыннар кételә.
- Май салкын килсә, икмәккә бай ел булыр.
-Беренче торналар күренгәч, борчак чәчәргә вакыт.
- Торналар бик еш күренсә – корылыкка.
-Май аенда коңгызлар күп булса, шулай ук корылык кételә.
- Майның егерме берендә яңгыр яуса, көз яңгырлы булыр.
- Айның соңгы көннәрендә, гадәттә, җиде елга бер тапкыр салкыннар күзәтелә.

**Яңалыклар**

- Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Дамирә Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның тууына 75 ел (1948–1993)
- Шагыйрь, мөгаллим Нәҗип Сибгатулла улы Думави (Тахтамышев)ның тууына 140 ел (1883–1933)
- Актёр, режиссёр, Татарстан Республикасының халык артисты Айдар Садри улы Хафизовның тууына 80 ел (1943–2020)
- Революцион хәрәкәт эшлеклесе Николай Эрнестович Бауманның тууына 150 ел (1873–1905)
- Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе ачылуга 150 ел (1873)

Ребус чишәбез
Нинди ил яшеренгән?




Ура каникуллар!!!

Санаулы гына уку көннәре калды. Укучылар барыгыз да һәр фәннән яхшы билгеләр алып, сәламәт булып уку елын тәмамлыйк. Илләрдә тынычлык булсын , яңа уку елын куанычлар белән каршы алырга язсын!!!